**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

04.02.2015 ел Яр Чаллы № 469

«2013 елга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 10 сентябрендәге 4930 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программасын төгәлләү зарурлыгына бәйле рәвештә,

КАРАР БИРӘМ:

1. «2013 елга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 10 сентябрендәге 4930 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2013 елга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программа исемендә «2013 елга» сүзләрен «2013-2015 елларга»сүзләренә алмаштырырга;

«2013 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа» кушымтасын (алга таба - программа) яңа кертелә торган редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Светлый путь» («Якты Юл») газетасында бастырырга һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан бирле үз көченә керә һәм 01.12.2014 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары, төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев